РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Ш. Марджани, дом 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы, 6нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» апрель 2025 № 115

**Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының 31.01.2025 №31 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2025 елның 28 февралендәге 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Әтнә район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында» 31.01.2025 ел, №31 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә (Алга таба – исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге статьяларны исемлектән төшереп калдырырга:

ТР КоАП 2.19. маддә Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонизацияләүче эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итү;

ТР КоАП 2.20. Составында сыеклаңдырылган углеводород газы булган гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен товарларны балигъ булмаганнарга ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук сыеклаңдырылган углеводород газын сулау юлы белән балигъ булмаганнарны куллануга җәлеп итү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Житәкчесе А.Ф. Каюмов